ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 г.Лениногорск № 1156

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган җир кишәрлегеннән милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган җир кишәрлегеннән милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма запросын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан

башкарыла. Бердәм портал тарафыннан запросның электрон формасының кырлары дөрес тутырылмавы ачыкланган очракта гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры электрон запрос формасында мәгълүмати хәбәр ярдәмендә бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар карау өчен уңайлы булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-17-41